ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, , 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Яна урамы, 4в йорты, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 3 29 январь 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ак-Юл авылында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 12 ноябрендәге 14 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Тарлау авылында 2024 елның 12 ноябрендәге 16 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Екатериновка авылында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 12 ноябрендәге 18 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Яссы-Тугай авылында 2024 елның 13 ноябрендәге 20 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Алабакүл авылында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 13 ноябрендәге 22 санлы,

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авылында 2024 елның 14 ноябрендәге 24 санлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы: Җ.Ә.Хөснетдинов

Димтамак авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның “29” январь
3 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган тормыш иптәшләре, хәрби хезмәттә булучылардан тыш, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2025 елның 29 гыйнварыннан 2025 елның 28 мартына кадәр үзара салым акчаларын түләүне башкара.

3. Түбәндәге очракларда нигезле сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт тормау,

б) авыру,

гражданнарга түләүне гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерү юлы белән, шулай ук кул куеп тапшыру, я почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын акча керү турындагы касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

8. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның “29” январь 3 санлы карарына 2 нче кушымта

Димтамак авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
_______________________________________________ нигезендә
_____________________Сезгә _______________елның “___”_____________кадәр үзара салым түләү буенча узган җыен чараларын гамәлгә ашыру буенча түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләнә торган сумма күчерергә кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү

Җитәкче ___________________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Димтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны __________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.